**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**2007 ел, 23 июль, 324 нче**
**КАРАР**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2007 ел, 6 декабрь, 692 нче; 2008 ел. 28 гыйнвар, 36 нчы;
2008 ел, 22 февраль, 99 нчы; 2008 ел, 29 май, 341 нче ;
2009 ел, 12 октябрь, 714 нче; 2010 ел, 15 июнь, 469 нчы;
2010 ел, 18 ноябрь, 908 нче; 2010 ел, 1 декабрь, 966 нчы;
2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 12 апрель, 287 нче
карарлары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасына үзгәрешләр кертү хакында" 2007 ел, 10 июль, ПУ-347 нче Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турында нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аппараты хезмәткәрләренең чик санын вазыйфа окладлары буенча айлык хезмәт өчен түләү фонды 630,3 мең сум күләмендә булган 140 берәмлек дип;

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 февраль, 99 нчы; 2010 ел, 15 июнь, 469 нчы; 2010 ел, 18 ноябрь, 908 нче карарлары редакциясендә)

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына хезмәт өчен бирелә торган машиналар лимитын 7 данә дип.

3.Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы министрның дүрт урынбасарын, шул исәптән бер беренче урынбасарны булдыруны рөхсәт итәргә.

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 15 июнь, 469 нчы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына 2010 елның 15 ноябреннән 2011 елның 1 апреленә кадәр вакытлыча өстәмә рәвештә министрның вазыйфа окладлары буенча айлык хезмәт өчен түләү фонды 6760 сум күләмендә булган бер урынбасарын булдыруны рөхсәт итәргә.

4. Көчен югалткан. - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 15 июнь, 469 нчы карары

5. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Сәүдә һәм тышкы икътисадый хезмәттәшлек министрлыгы мәсьәләләре” 2005 ел, 6 июль, 321 нче карарын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Сәүдә һәм тышкы икътисадый хезмәттәшлек министрлыгы коллегиясенең составын һәм санын раслау турында” 2005 ел, 14 октябрь, 488 нче карарын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Сәүдә һәм тышкы икътисадый хезмәттәшлек министрлыгы турында нигезләмәне раслау хакында” 2001 ел, 28 июль, 494 нче карарын.

6. Бу Карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 23 июль, 324 нче
Карары белән
расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2010 ел, 15 июнь, 469 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче;
2011 ел, 12 апрель, 287 нче
карарлары редакциясендә)

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык) сәнәгать һәм куллану базары өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, халыкара, төбәкара һәм тышкы икътисадый элемтәләр өлкәсендә идарә итү, чит ил инвестицияләрен җәлеп итү, республика предприятиеләре продукциясен тышкы һәм эчке базарларга чыгару, республика максатчан программаларын формалаштыру, федераль максатчан программаларны формалаштыруда катнашу функцияләрен тормышка ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.

1.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге һәм теләсә кайсы ведомствога караган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән эшчәнлекнең билгеләнгән төрләрендә үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

1.3. Министрлык федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара мөнәсәбәттә тора.

1.4. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таяна.

1.5. Министрлык юридик зат була, аның үз мөстәкыйль балансы, банк учреждениеләрендә хисап исәбе һәм башка исәпләре, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән мөһере һәм үз символикасы була.

1.6. Министрлык урнашкан урын (юридик адресы): 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 4 нче йорт.

## 2. Министрлыкның бурычлары

2.1. Министрлыкның төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1.1. Республика территориясендә җитештерү көчләрен оптималь һәм нәтиҗәле урнаштыруны тәэмин итү һәм куллану базарын үстерү максатларында, республиканы территориаль үстерү буенча бердәм схема нигезендә дәүләт сәнәгать сәясәтен эшләүдә һәм тормышка ашыруда катнашу.

2.1.2. Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, шулай ук аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыруда катнашу.

2.1.3. Бердәм дәүләт инвестиция һәм инновация сәясәтен, инвестиция активлыгын стимуллаштыру чараларын тормышка ашыруда катнашу.

2.1.4. Татарстан Республикасының халыкара, төбәкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен камилләштерү һәм үстерү, сан һәм сыйфат ягыннан аларның параметрларын яхшырту, республиканың икътисад комплексын дөньякүләм хезмәт бүленеше системасына нәтиҗәле җәлеп итү өчен шартлар тудыру, тышкы сәүдә әйләнеше структурасын оптимальләштерү.

2.1.5. Татарстан Республикасы предприятиеләре продукциясен ерак һәм якын чит илләр, Россия Федерациясе төбәкләре һәм Татарстан Республикасы базарларына чыгару.

2.1.6. Чит илләр инвестицияләрен Татарстан Республикасы территориясенә җәлеп итү.

## 3. Министрлыкның функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада китерелгән эшчәнлек төрләре буенча сәнәгать белән идарә итү (03.01 <*>)[1];

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлеге белән идарә итү (01.03 <*>), шул исәптән:

Татарстан Республикасы вәкиллекләре һәм сәүдә йортлары эшчәнлеген яраштыру (01.03.1 <*>);

якын һәм ерак чит илләр белән икътисадый, мәгълүмати һәм мәдәни элемтәләргә ярдәм итү (шул исәптән ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә) (01.03.2 <*>);

чит илләрнең федератив дәүләтләре субъектларының дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеге белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.03.3 <*>);

---

[1] Кодны билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.

эчке товар базарын аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүне җайга салу (03.05 <*>);

социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлеген билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү (03.07 <*>).

3.2. Министрлык түбәндәгеләр белән үзара мөнәсәбәттә тора:

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

озак вакытка исәпләнгән чорга социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01.1 <*>);

планлаштырыла торган елга социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01.2 <*>);

территориаль планлаштыру схемасын һәм Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын тормышка ашыру планын эшләүне тәэмин итү (01.05.01 <*>);

җитештерү билгеләнешендәге продукциягә, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә җайга салу (01.09.2 <*>);

сәнәгать һәм куллану базары өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.10 <*>);

сәнәгать һәм куллану базары өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11 <*>);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02 <*>);

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигый мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06 <*>);

Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02.01 <*>);

Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә транспорт комплексы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03 <*>);

Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы белән куллану базарын җайга салу өлкәсендә сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02 <*>);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13 <*>);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге акцияләрдән (өлешләрдән) файдалану белән идарә итү (01.07.02 <*>);

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.07.03 <*>);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01 <*>);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05 <*>);

Татарстан Республикасының Энергетика министрлыгы белән энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.14 <*>);

Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнештә йөртү һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе белән этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнештә йөртү өлкәсендә хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.05.01 <*>).

## 4. Министрлыкның вәкаләтләре

4.1. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә, бу Нигезләмәнең 3 бүлегенә таянып, түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

4.1.1. Сәнәгать, инновация, инвестиция һәм кадрлар сәясәте, шулай ук куллану базарын һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерү стратегиясен эшли. Татарстан Республикасы территориясендә теләсә кайсы ведомствога караган, теләсә кайсы милек рәвешендәге һәм теләсә кайсы финанслау чыганаклары булган җитештерү объектларын урнаштыру, төзү, реконструкцияләү буенча норматив актлар проектлары бәяләмәләрен, шулай ук инвестиция проектлары, техник-икътисадый нигезләүләрне билгеләнгән тәртиптә әзерләүне һәм килештерүне гамәлгә ашыра.

4.1.2. Кыска вакытка, уртача вакытка һәм озак вакытка исәпләнгән чорларга сәнәгатьне һәм куллану базарын социаль-икътисадый үстерүнең комплекслы фаразын эшләүне оештыра һәм яраклаштыра.

Җитештерү көчләрен урнаштыру һәм үстерү буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеген яраштыруда катнаша.

4.1.3. Республика товар җитештерүчеләренә товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне базарга чыгаруда һәм яклауда (шулай ук Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең куллану базарында) булышлык күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру эшчәнлеген башкара.

4.1.4. Республиканың эчке базарын тулыландыру мониторингын гамәлгә ашыра.

4.1.5. Куллану базары инфраструктурасын камилләштерә.

4.1.6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары белән берлектә, билгеләнгән тәртиптә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр

иминлеген тәэмин итү өлкәсендә республика максатчан программалары проектларын эшли.

4.1.7. Сәнәгать һәм куллану базары кадрларын һәм башка белгечләрен әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аларның квалификациясен күтәрүне гамәлгә ашыруда катнаша, моның өчен Татарстан Республикасының фәнни базасыннан, Россиянең һәм чит илләрнең уку йортларыннан файдалана; чит ил фирмаларында, компанияләрендә, фәнни-тикшеренү үзәкләрендә һ.б. Татарстан Республикасыннан белгечләрнең стажировкасын оештыруда катнаша.

4.1.8. Төбәк лотереяларын үткәрүгә, төбәк лотереяларын теркәүгә, төбәк лотереяларының дәүләт реестрын алып баруга рөхсәтнамәләр бирүне һәм Татарстан Республикасы территориясендә төбәк лотереяларын үткәрүне, шул исәптән лотереялар үткәрүдән алына торган акчадан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

4.1.9. Икътисадның төрле тармакларына караган предприятиеләр арасында, аларның җитештерү-хуҗалык эшчәнлеге йомгакларының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм республиканың җитештерү көчләрен балансланган тәртиптә үстерү максатларыннан чыгып, җитештерү кооперациясен (субконтрактациясен) һәм аутсорсинг технологияләрен үстерүдә катнаша.

4.1.10. Максатчан программалар проекларын билгеләнгән тәртиптә килештерүне һәм сәнәгать һәм куллану базары өлкәсендә федераль һәм республика максатчан программаларын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлеген яраштыруны гамәлгә ашыра.

4.1.11. Татарстан Республикасы икътисадын үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен, дәүләтнең социаль-икътисадый программаларын тормышка ашыру мәсьәләләре буенча хөкүмәт карарларын эшләүдә катнаша.

4.1.12. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләре һәм аларның күрсәткечләре буенча алдагы өч елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары исемлеге буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша.

4.1.13. Сәнәгать җитештерүенең өстенлекле тармакларын билгеләү буенча, беренче чиратта дәүләт ярдәме күрсәтелергә тиешле предприятиеләр һәм башка коммерция оешмалары буенча, шулай ук закон белән билгеләнгән тәртиптә үзгәртеп оештырылырга йә бетерелергә тиешле предприятиеләр һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар буенча тәкъдимнәр әзерли.

4.1.14. Халыкара сыйфат һәм сертификатлау стандартларын кертү нигезендә республика продукциясенең сыйфатын һәм конкурентлылык сәләтен күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны формалаштыра һәм аларны тормышка ашыру өчен шартлар тудыра.

4.1.15. Министрлыкның, эшчәнлекләре Министрлык эшчәнлегенә бәйле булган яки аның карамагы өлкәсендәге оешмаларның мобилизация әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, шулай ук бу чараларны методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче карары редакциясендә)

4.1.16. Татарстан Республикасының халыкара, төбәкара һәм тышкы икътисадый элемтәләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру өчен шартлар тудыра.

4.1.17. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары белән берлектә, Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеген үстерү фаразын эшли, Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган товарларның тышкы һәм эчке базарларына маркетинг тикшеренүләрен үткәрүне тәэмин итә.

4.1.18. Резидентларны «Алабуга» махсус икътисадый зонасына җәлеп итү эшләрен оештыруны гамәлгә ашыра.

4.1.19. Россия Федерациясе субъектлары, чит илләрнең федератив дәүләтләре субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре, халыкара оешмалар белән халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы килешүләре проектларын эшли.

4.1.20. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары белән берлектә, Татарстан Республикасының ерак һәм якын чит илләрдәге, Россия Федерациясе субъектларындагы вәкиллекләрен финанслауга бюджет гаризалары проектларын һәм тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендәге федераль программалар һәм проектлар кысаларында республиканың бюджет йөкләмәләрен формалаштыру өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты проектын эшләүдә катнаша.

4.1.21. Татарстан Республикасының ерак һәм якын чит илләрдәге, Россия Федерациясе субъектларындагы вәкиллекләре эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыра.

4.1.22. Татарстан Республикасының сәнәгать предприятиеләренә био- һәм нанотехнологияләрне кертү эшләрен оештыруны гамәлгә ашыра.

4.1.23. Наноиндустрия өлкәсендә эшләнмәләр белән шөгыльләнә торган Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары реестрын алып баруны гамәлгә ашыра.

4.1.24. Сәнәгать нанопроектларына аларны Татарстан Республикасы предприятиеләрендә тормышка ашыруның икътисадый яктан максатка ярашлы булу-булмавына экспертиза үткәрә.

4.1.25. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән берлектә, сәнәгать һәм куллану базары өлкәсендәге инвестиция проектларына икътисадый экспертиза үткәрә.

4.1.26. Дәүләт хакимияте башкарма органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен оештыруны гамәлгә ашыра.

4.1.27. Якын һәм ерак чит илләрдә Татарстан Республикасы вәкиллекләрен гамәлгә куюны тиешле федераль органнар белән килештерүне гамәлгә ашыра.

4.1.28. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы органнары белән берлектә, Татарстан Республикасында халыкара сәүдә-сәнәгать күргәзмәләрен, ярминкәләрен, семинарларын, шулай ук чит илләрдә республика

күргәзмәләрен һәм экспозицияләрен оештыру һәм үткәрү планнарын эшли һәм яраштыруны гамәлгә ашыра.

4.1.29. Халыкара тышкы икътисадый эшчәнлекне мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шул исәптән Татарстан Республикасы, продукция җитештерүчеләр турында, республика территориясендә чит илләр инвестицияләрен хокукый җайга салу турында белешмә-мәгълүмати материаллары бастырып чыгаруны оештыра; Министрлыкның бу Нигезләмә белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы турында мәгълүмат әзерли һәм чит илләр һәм Россия басмаларында урнаштыра.

4.1.30. Ваклап сату базарларын оештыру эшләрен, шулай ук Татарстан Республикасының ваклап сату базарларында товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген яраштыруны гамәлгә ашыра.

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 12 апрель, 287 нче карары редакциясендә)

4.1.31. Татарстан Республикасы базарлары реестрын, сәүдә реестрын, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары реестрын формалаштыра һәм алып бара.

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 12 апрель, 287 нче карары редакциясендә)

4.1.32. Татарстан Республикасы территориясендә куллану базарындагы эшчәнлек өлкәсендә хокук актлары проектларын эшли.

4.1.33. Агымдагы һәм перспективалы чорга куллану базарын үстерү буенча дәүләт программаларын эшләүне һәм тормышка ашыруны тәэмин итә, куллану базарын үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәте концепцияләрен әзерләүне гамәлгә ашыра.

4.1.34. Кыска вакытка, уртача вакытка һәм озак вакытка исәпләнгән чорларга тармакны икътисадый һәм социаль үстерү фаразлары проектларын эшли.

4.1.35. Куллану базарындагы эшчәнлек өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын булдыру эшен үткәрә, тармакны методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне оештыра.

4.1.36. Тармакның квалификацияле кадрларга, перспективага эшче көчләргә булган ихтыяҗын фаразлауны билгеләүдә катнаша, һөнәр белеме учреждениеләренә дәүләт йөкләмәләрен формалаштыру, тармак хезмәткәрләрен әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү турында тәкъдимнәр әзерли.

4.1.37. Татарстан Республикасы территориясендә куллану базарындагы эшчәнлекне гамәлгә ашыруга һәм билгеле бер товар базарының торышына мәгълүмати-аналитик күзәтү үткәрә.

4.1.38. Татарстан Республикасы территориясендә куллану базарындагы эшчәнлекне үстерүгә ярдәм итә торган чаралар эшләүне һәм тормышка ашыруны тәэмин итә.

4.1.39. Җирле үзидарә органнары тарафыннан куллану базарының стационар булмаган объектларын урнаштыру схемаларын эшләү һәм раслау тәртибен билгели.

4.1.40. Ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату тәртибен билгели.

4.1.41. Республика өчен (шул исәптән аның составына керә торган муниципаль берәмлекләр өчен дә) халыкның сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин ителеше нормативларын эшләүне тәэмин итә.

4.1.42. Эчке сәүдә һәм куллану базары өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм норматив-хокукый җайга салуны тормышка ашыра.

4.1.43. Куллану базары өлкәсендә эшмәкәрлек эшчәнлеген һәм конкуренцияне үстерүгә, куллану базары инфраструктурасын үстерүгә булышлык күрсәтә.

4.1.44. Куллану базарының торышына комплекслы анализ үткәрә, куллану базары үсешен фаразлауны, куллану базары үсешенең төп күрсәткечләрен әзерләүне гамәлгә ашыра.

4.1.45. Куллану базары өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларыннан чыгып, уртак эшчәнлекне яраштыру буенча җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итә.

## 5. Министрлыкның хокуклары һәм бурычлары

5.1. Министрлык үз функцияләрен башкару өчен түбәндәге хокукларга ия:

5.1.1. Татарстан Республикасының норматив актлары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарыннан, учреждениеләрдән, оешмалардан, предприятиеләрдән, вазыйфаи затлардан Министрлыкка йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле түләүсез мәгълүматлар, документлар һәм материаллар сорарга һәм алырга.

5.1.2. Министрлык эшчәнлеге өлкәсенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарын, бәйсез аудитор, консалтинг фирмаларын, фәнни һәм башка оешмаларны, галимнәрне һәм белгечләрне билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә.

5.1.3 Билгеләнгән тәртиптә, дәүләт хакимиятенең республика территориясендә урнашкан бүтән башкарма органнары, башка оешмалар җитәкчеләрен һәм белгечләрен җәлеп итеп, үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча киңәшмәләр җыярга, аларның хәбәрләрен, хисапларын тыңларга.

5.1.4. Министрлык балансына тапшырылган мөлкәт белән оператив идарә итүне гамәлгә ашырырга.

5.1.5. Яраштыру һәм киңәшү, консультация органнары һәм Министрлык компетенциясе өлкәсендә эшли торган башка оешмалар төзергә һәм аларның эшендә катнашырга.

5.1.6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомствоның аерым билгеләрен гамәлгә куярга һәм алар белән Министрлык хезмәткәрләрен һәм эшчәнлекләрен билгеләнгән өлкәдә гамәлгә ашыручы башка затларны бүләкләргә.

5.1.7. Тармакның үзен аеруча яхшы яктан күрсәткән хезмәткәрләрен мактаулы исемнәр бирүгә, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә билгеләнгән тәртиптә тәкъдим итәргә.

5.1.8. Министрлыклар һәм ведомстволарның, учреждениеләрнең сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек турындагы хөкүмәтара килешүләр буенча Татарстан Республикасы йөкләмәләрен үтәвен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга.

5.1.9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кушуы буенча хөкүмәтара комиссияләр, төбәкара ассоциацияләр, халыкара икътисадый оешмалар эшендә катнашырга.

5.1.10. Ерак һәм якын чит илләрнең, Россия Федерациясе субъектларының Татарстан Республикасына дәүләт, хөкүмәт һәм башка делегацияләре визитлары вакытында чараларны беркетмәләр белән тәэмин итүдә катнашырга.

5.1.11. Судларга (шул исәптән арбитраж судларга) дәгъвалар һәм гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Министрлык компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча законнарны бозуга бәйле эшләрне караганда катнашырга.

5.1.12. Министрлык эшчәнлеге өлкәсенә керә торган мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрү өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә бәйсез аудиторлык, консалтинг фирмаларын һәм аерым белгечләрне җәлеп итәргә.

## 6. Министрлык эшчәнлеген оештыру

6.1. Министрлыкка Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән тәртиптә вазыйфага билгеләнә һәм аннан азат ителә торган министр җитәкчелек итә.

Министрның урынбасарлары министр тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән вазыйфага билгеләнә һәм аннан азат ителә.

6.2. Министр:

Министрлык эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне бер үзе хәл итү тәртибендә гамәлгә ашыра һәм Министрлыкка йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен шәхсән җавап бирә;

Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрне раслый, Министрлык хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, министр урынбасарлары арасында бурычларны бүлә;

Татарстан Республикасының чит илләрдәге һәм Россия Федерациясе субъектларындагы сәүдә-икътисад вәкилләре кандидатураларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен кертә;

үз компетенциясе чикләрендә боерыклар чыгара, аларның үтәлешен тикшерүдә тоту эшен оештыра;

хезмәткәрләрнең билгеләнгән саны, хезмәт өчен түләү фонды һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Министрлык аппаратын тотуга чыгымнар сметасын, штат расписаниесен раслый.

6.3. Министрлыкта төп бурычы тышкы икътисадый эшчәнлек, сәнәгать, сәүдә, продукцияне базарга чыгару, чит ил инвестицияләрен җәлеп итү өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле мөһим мәсьәләләр буенча карарлар эшләү булган коллегия оештырыла.

Коллегия составына министр, вазыйфалары буенча аның урынбасарлары, структур бүлекчәләр һәм дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары

җитәкчеләре, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләре, галимнәр һәм белгечләр керә.

Коллегия составы һәм аның әгъзалары саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Министр коллегиянең рәисе була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Аппараты
Җитәкчесе
Ш.Х.Гафаров

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 23 июль, 324 нче
карары белән
расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ СТРУКТУРАСЫ

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 15 июнь, 469 нчы;
2010 ел, 18 ноябрь, 908 нче карарлары редакциясендә)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| МИНИСТР | | | | | |
| | | | | | Ярдәмче |
| Министрның беренче урынбасары | Министр урынбасары | Министр урынбасары | Министр урынбасары | Эшләр идарәсе | Пресс-секретарь |
| Машина төзелеше комплексы бүлеге | Халыкара һәм тышкы элемтәләрне икътисадый яраштыру бүлеге | Төбәкара элемтәләрне үстерү бүлеге | Җыелма бүлек | Оештыру эшләре бүлеге | Икътисадый иминлек буенча төп белгеч |
| Оборона комплексы бүлеге | Рәсми беркетмә бүлеге | Куллану базарын һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерү бүлеге | Сәнәгатьне һәм сәүдәне фаразлау һәм үстерү бүлеге | Эш башкару бүлеге | Мобилизация эше һәм серле документлар белән эшләү бүлекчәсе |
| Сәнәгать инновацияләре һәм инвестицияләре бүлеге | Тәрҗемә бүлеге | Сәүдәне, көнкүреш хезмәтләре күрсәтүне һәм җәмәгать туклануын үстерү программаларын тормышка ашыру бүлеге | Предприятиеләрнең агымдагы җитештерү-хуҗалык эшчәнлеген анализлау | Гомуми бүлек | Юридик бүлек |
| Агач эшкәртү, азык-төлек һәм җиңел сәнәгать бүлеге | Республика вәкиллекләре белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге | Күргәзмәләр эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру бүлеге | Корпоратив идарә бүлеге | Мәгълүмат технологияләрен үстерү бүлекчәсе | Финансларны планлаштыру, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге |
| | | | | Дәүләт заказы бүлекчәсе | Кадрлар бүлеге |

БАРЛЫГЫ: 140 кеше

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 18 ноябрь, 908 нче карары)

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Аппараты
Җитәкчесе
Ш.Х.Гафаров